Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

№2 (20)

Гыйнвар-февраль, 2017 нче ел



Бу санда:

Гимназия сулышы 1

Гимназия йолдызлары 2

Беренче президентыбызга багышланган махсус кушымта 3-6

Иҗади сәхифә 7-8

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Инглиз телендә сөйләшү көне



“Инглиз телендә сөйләшү көне” кысаларында гимназия төрле чаралардан гөрләп торды. Көн инглиз телендә иртәнге зарядка белән башланды. Барлык укучылар үзара инглиз телендә аралашырга тырышты. Хәтта укытучылар арасында “Гугл-переводчик” ярдәмендә репликалар өйрәнеп, бер-берсе белән аралашучылар булды. Беренче коймак төерле була, диләр. Бу көн бик мавыктыргыч узды, “төерләр” сизелмәде.



### «Талантлар иле» Бөтенроссия проекты

«Талантлар иле» Бөтенроссия проекты гимназия укучыларын елдан-ел күбрәк җәлеп итә. 2016-2017 нчы уку елының беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча федераль дәрәҗәдә җиңү яулаучы укучыларыбыз шактый күп. Менә алар: Рәхимов Данис, Хәлиуллин Алмаз, Кәримова Ләйлә, Баянов Шамил, Латипова Камилла, Саламаев Руслан, Усманова Алина, Фахруллин Булат, Бәдертдинова Динә, Зәйниева Әнисә, Магданова Ләйсан, Шәмсетдинова Гүзәл, Салихова Динара һәм Мөхәмәтханова Айгөл. Булдырасыз, укучылар! Афәрин!

### Фәнни-практик конференцияләрдә җиңүләр

Гыйнвар аенда “XV Раштуа укулары” укуларында I дәрәҗә Диплом белән 1б класс укучысы Салихҗанова Камилә (Исмәгыйлова Г.Ф.), III дәрәҗә Диплом белән 2а класс укучысы Хатипова Ралина (Мортазина Л.Г.) бүләкләнде. 1б класс укучысы Әһлиуллина Гөлзирәнең эше кызыксындыру Дипломы белән бәялəп үтелде (Исмагилова Г.Ф.).

«Что, как и почему – разберусь и объясню» Республикакүләм фәнни-практик конференциясенең 1 нче дәрәҗә Дипломына 4 нче класс укучысы Бариева Илина лаек булды (җитәкчесе: Бариева Л.Ф.).








### Кышкы спартакиада



Мөслим муниципаль районы педагоглары арасында “Кышкы спартакиада” уеннары узды. Гимназия директоры А.Ф.Мирзаянов турникта тартылу буенча район күләмендә беренче урын, ә гимназия командасы гомуми зачетта икенче урын яулады. Укытучыларыбыз үз хезмәтләренең остасы булу өстенә, спортта да сынатмыйлар. Без сезнең белән горурланабыз! Афәрин!

## ГИМНАЗИЯ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

### “Ел укытучысы - 2017” бәйгесе

Бөтенроссия “Ел укытучысы” бәйгесенең муниципаль туры старт алды. Гимназия укытучылары һәр елдагыча бик актив катнаштылар, Мөслим лицее, Г.Тукай мәктәбе базаларында ачык дәресләр күрсәттеләр. Тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Р.Р.Мөхәмәтдинова, башлангыч сыйныфлар укытучысы Э.С.Ермолаева, инглиз теле укытучылары Р.Г.Кадыйрова, А.Р.Шәрифуллин, рус теле һәм әдәбияты укытучысы И.Т.Галиева ачык дәресләр, мастер-класслар күрсәттеләр. Беренче этапны үтеп, Римма Гайсовна Кадыйрова зона этабында уңышлы чыгыш ясады.





### Олимпиада призерларын котлыйбыз

Гимназия укучылары Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында яңа үрләр яулый. 10 нчы б сыйныф укучысы Сафиуллин Ренат физкультура буенча Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында призер (укытучысы - Сәетгалиев И.Н.), 9 нчы а сыйныфы укучылары Зиязова Миләүшә һәм Фәхертдинова Айгөл исә биология буенча призер, 9 нчы а сыйныфы укучысы Фәхертдинова Айгөл, 11 нче сыйныф укучысы Әһлиуллина Язилә экология буенча призер (укытучылары - Бариева Л.Ф.), 11 нче сыйныф укучысы Әһлиуллина Язилә татар әдәбиятыннан, 10 нчы а сыйныф укучысы Шамукаева Эльвина татар теленнән призер (укытучылары - Тимергалиева Э.В.) булдылар. Тырыш хезмәт, белемгә омтылыш шулай югары бәя ала. Чын күңелдән котлыйбыз! Укучыларыбызның уңышлары дәвамлы булсын!







## БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗГА - 80 ЯШЬ

### Тормыш юлы



Минтимер Шәрип улы Шәймиев 1937 елның 20 гыйнварында хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында крестьян гаиләсендә туа.

М.Ш.Шәймиевнең бабасы – Шәймөхәммәт урта хәлле, таза тормышлы игенче булган. Коллективлаштыру елларында, кулак дип санап, аны йортыннан, мал-туарларыннан мәхрүм иткәннәр. Минтимер Шәриповичның атасы – Шәһишәрип ага Шәймиев бөтен гомере буена авыл хуҗалыгында эшли (26 ел дәвамында колхоз рәисе булып тора).

1954 елда М.Ш.Шәймиев Пучыда урта мәктәпне тәмамлый һәм Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Казан авыл хуҗалыгы институтының механикалаштыру факультетын тәмамлаганнан соң (1959 ел) авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендә эшли.

1969-1983 елларда – ТАССРның мелиорация һәм су хуҗалыгы министры.

1983 елда ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары.

1983-1985 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре.

1985-1989 елларда – ТАССР Министрлар Шурасы Рәисе.

1989-1990 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре.

1990 елда ТАССР Югары Шурасы Рәисе итеп сайлана. Шул елда Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителә.

1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасының беренче Президенты итеп сайлана. Татарстанның күпмилләтле халкы республикада тынычлык һәм иминлекне ныгыту, катлаулы социаль-икътисадый проблемаларны хәл итү буенча М.Ш.Шәймиев тырышлыгына югары бәя бирә. Ике мәртәбә (1996 елның 24 мартында һәм 2001 елның 25 мартында) ул яңадан Татарстан Республикасы Президенты итеп сайлана.

1994-2001 елларда Русия Федерациясенең Федераль Мәҗлесенең Федерация Шурасы әгъзасы.

2005 елның 25 мартында Русия Федерациясе Президенты Владимир Путин күрсәтүе буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан М.Ш.Шәймиевкә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре бирелә.

Русия Федерациясе Дәүләт Советы әгъзасы (2000-2001 елларда Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы).

2001 елның 1 декабреннән "Бердәм Русия" партиясенең Югары Советы рәистәше.

ТР Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевның вәкаләтләр чоры 2010 елның 25 мартында бетте.

2010 елның 21 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе итеп билгеләп куелды.

2010 елның апреленнән “Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика Фонды” коммерциячел булмаган оешмасының Попечительләр Советы Рәисе булып тора.

Россиянең Иҗтимагый телевидениесе Советы әгъзасы. Россия тарих җәмгыяте әгъзасы.

Өйләнгән, хатыны Сәкинә Шакир кызы, ике улы – Радик һәм Айрат.

### Тормыш сукмагында Мөслим дә бар

Минтимер Шәймиев, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан соң, үзенең хезмәт юлын Мөслим районы үзәгендә, ремонт-техник станциянең баш инженеры буларак башлап җибәрә. Ул болай да Мөслимнән 40-45 чакрым чамасында урнашкан Әнәк авылында туып-үскән егет. Минтимер мәктәптә укып йөргән чакларында Әнәк - үзәге Пучы авылы булган Калинин районына карый. «Мәктәбендә үзем укыган Пучыга әйләнеп кайтырмын», дип канатланып йөргән егетнең хыяллары чынга ашмый кала. 1958 елда әүвәл район үзәгендә булган МТСларны юкка чыгаралар да алар урынына колхозлардагы комбайн-тракторларга техник ярдәм күрсәтергә тиешле РТСларны ачып җибәрәләр. Әле район үзәге саналган Пучыга кайтып хезмәт кую да начар булмас иде. Үч иткәндәй, нәкъ Минтимер Шәймиев диплом алган 1959 елда Калинин районын да юкка чыгаралар һәм элек аның составында булган 6 хуҗалыкны Мөслим районына кушалар. Тәкъдир сынавына буйсынып, Минтимер Шәймиевкә Мөслимгә юнәлергә туры килә.



***Шәймиев М.Ш.:*** *“Минем иң гүзәл елларым Мөслимдә үтте, - дип искә ала ул соңрак үзенең тәүге хезмәт елларын. - Бу җир минем өчен бик изге. Яшьлек елларында бергә эшләгән дусларым, танышларым гомер буе онытылмас хатирә булып истә калды».*

## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

Минтимер Шәймиев күпбалалы гаиләдә тугызынчы бала булып туа. «Мондый гаиләдә сабырлыкка, олыларны тыңларга, бердәмлеккә өйрәнәсең. Монда мин-минлек, үз-үзеңне генә ярату сыйфатлары юк».

Кушаматы – Чапкын. Бу – нәселдән бирелгән кушамат. Минтимер аганың бабасын кулак дип тапканнар, әмма сөргенгә сөрмәгәннәр. Ул Сабантуй өчен чабышкы атлар асраган. Аларны бу көн өчен ел буе әзерләгән һәм Минзәлә өязендә беренчелекне берәүгә дә бирмәгән. «Чапкын» кушаматы шулай ябышып калган.

Балачактан шахмат уйный. «Яшьтәшләр белән картон кәгазьгә квадратлар сызабыз. Бу – шахмат тактасы. Ә фигураларын агачтан кисеп ясыйбыз. Шахматны язын, «коровник» түбәсендә, имтиханга әзерләнгәндә ял арасында уйныйбыз. Безнең заманда бит 7 сыйныфтан башлап, һәр ел саен 5-9 имтихан тапшырырга кирәк иде».

Азарт белән укый. «Тынгысыз малай булдым. Безнең авыл аша узып районга математика укытучысы эшкә йөри иде. Әгәр мин берәр гамәлне чишә алмасам, ничек чишәргә кирәклеген сорарга дип, аны саклап торам».

Балачак хыялы – гармунда уйнарга өйрәнү. «Авылда гармун тартучы егетләр бар иде. Абый белән минем гармунда уйнавымны ишетү – әтинең зур хыялы иде. Әмма миннән берни дә килеп чыкмады. Гармунчыларга карата яшерен көнләшү бар иде. 60 ка якынлашканда бу теләк кабат калкып чыкты. Буш вакытларымда кулыма гармун ала башладым. Уйнап җибәрдем бит. Бу могҗиза! «Алмагачлары», «Озата барма», «Күбәләгем», «Җидегән чишмә» не гармунда суза алам».



Китап укырга ярата. Бигрәк тә Тукайны. «Мин гомерем буе Тукай шигърияте белән мавыктым. Такташ иҗаты да ошый. Ул – безнең Маяковский. Район китапханәсендәге бөтен китапны укып чыктым. Татар язучыларыннан Әмирхан Еники, Кави Нәҗми, чит ил әдәбиятыннан Виктор Гюго тирән тәэсир ясады. Хәзер кабат Достоевскийны укыйсым килә. Аның иҗат киңлеген аңлау соңрак килде».

Гадел прокурор булырга теләли. «Әти колхоз рәисе булып эшләгәндә, чак кына төрмәгә утыртмый калдылар. 1949 елда халык ачлыктан шешенде, язгы чәчүгә төшәрлек хәл юк иде. Әти авылдашларга җәмәгать туклануы булдырды. Халыкны ашатуны оештыру карарын ул үзе генә кабул иткән. Ул вакытта бер бөртек ашлык өчен дә төрмәгә тыгалар. Әтине җәй буе прокурор Кашаповка йөртеләр. Аны төрмәдән бары тик колхоздагы икмәк уңышының күп җыелуы гына саклап калды. Шул вакытта мин үз-үземә гадел прокурор булырга сүз бирдем. Әмма соңгы мизгелдә әти МТСта инженерлар әзерли торган курс хакында белдерү күреп алды. Безнең гаиләдә әти карарына каршы килү гадәте юк иде».

Тормыш иптәше белән бию таныштыра. Авылдан шәһәргә килгән вакыт – бии белмим. Әй, шул горурлыкка бәрә дә инде! Бәхеткә, институтта бию түгәрәге оештырдылар. Гади генә түгел, бал биюләре өйрәндек. Бу минем тормышымда зур роль уйнады. Сәкинә белән мине бию таныштырды».

Гомер буе җитәкче. «Институтны тәмамлаганнан соң нибары 9 ай инженер булып эшләдем. Һәм шуннан китте... Баш инженер, директор, министр, Хөкүмәт җитәкчесе... Президент. Кызык, минем карьерада түбәнгә төшә булмаган икән бит».

Эт тоту – гомерлек хыялы. «Вакытым җитмәү сәбәпле, этем булмады. Аннан соң Сәкинә дә каршы булды моңа, ул песиләр ярата. Әмма Президент срогы бетәргә бер ел кала, эт алдык. Кушаматы – Тукай персонажы «Махмай». Минем белән урамга чыгуны көтеп ала. Акыллы эт».

***Махсус кушымта өчен материалларны Регина Шәйгәрданова әзерләде***

# ГИМНАЗИЯ ДИРЕКТОРЫ АЗАТ ФӘРИТ УЛЫНА АЧЫК ХАТ

***Хөрмәтле Азат Фәритович!***

Мин 6 нчы б сыйныфында укыйм, үзебезнең гимназиябезне бик яратам, гел “5” билгеләренә укыйм, түгәрәкләргә йөрим, интеллектуаль ярышларда, фән бәйгеләрендә катнашам. Барлык укытучыларымны, Сезне хөрмәт итәм. Сез - гимназия өчен иң кирәкле кеше, чөнки барлык матур яңалыкларны кертүче - Сез. Минем Сезгә берничә үтенечем бар. Беренчесе - гимназиядә көчле Wi-fi булуын теләр идем. Юк, юк, тәнәфестә уеннар уйнар өчен түгел. Дәресләрдә укытучылар безгә интернет челтәре ярдәмендә күбрәк мәгълүмат бирә алырлар иде, юкса дәреснең кадерле минутлары әкрен генә әйләнеп, кочкә кушыла торган интернетны көтеп үтеп китә. Икенчесе – гомуми чишенү урыны турында. Анда бик кысан, аяк киемнәрен куярга урыннар җитми, алар таптала, югала. Чишенү урыннарын башкача уйларга вакыт җиткәндер. Минем теләкләремне искә алырсыз, дип уйлыйм.

***Шамил Баянов***

***Хөрмәтле Азат Фәритович!***


Без, 6 нчы б сыйныфы укучылары, Сезне чын тылсым-чы итеп күрәбез. Инициативалы, алдан күрә белүче, бай фантазияле, тынгысыз җитәкче буларак, гимназия тормышына һәрвакыт ниндидер яңалык кертәсез. Ел саен гимназиянең алдынгы укучыларына, аларның әти-әниләренә матур, җылы эчтәлекле хатлар җибәрәсез. Бары тик гимназиядә генә укучыларның фәнни конференциясендә җиңеп, акча сертификаты белән бүләкләнергә, аны үзебезнең ашханәдә төрле тәмле ризыкларга алыштырырга була.

Безнең үз кинотеатрыбыз барлыкка килде, хоккей мәйданчыгы заманча төс алды. Макулатура җыйган акчага кызларның технология кабинетын кухня гарнитуры белән җиһазладыгыз, этажларда ял почмаклары оештыру турында кайгыртып йөрисез.

Бер дә шикләнмибез, безнең әле һәр укучыга нетбуклары булган Wi-fi уку залыбыз да, ишектән кергәндә безне билгели торган электрон карталар, һәр укучының үз кием шкафы, әр-яңа технологияләрне кулланырга мөмкинлек бирүче класс кабинетларыбыз да булыр.

***Диләрә Нуриева***

***Азат Фәритович!***



Безнең классның күптәнге бер хыялын тормышка ашырырга ярдәм итегез. Зур автобуска утырып, Мәскәү шәһәренә экскурсиягә барырга иде. Юлда иптәшләр белән аралашып, төрле шәһәрләр белән танышып кайтыр идек. Кызыл мәйдан, Кремль, Мавзолейны, “Бородинская битва” панорамасын күрәсе, Арбатта, метрода йөрисе, ап-ак тешле негрларны күрәсе килә. Без сезгә ышанабыз.

***Алмаз Ишматов***



***Азат Фәритович!***

Мин үзебезнең гимназия территориясендә һәр классның үз ял урыны булуын теләр идем. Күләгәдә утырып ял итәргә, төрле уеннар уйнарга, иптәшләребез белән аралашырга рәхәт җир булыр иде ул. Без, үз чиратыбызда, үз почмакларыбызны үзебез теләгәнчә төрле дизайн белән бизәр идек.

Гимназия - перспективалы белем йорты. Биредә белем һәм тәрбия алган укучылар беркайда да югалмый. Гимназияне тәмамлаган укучылар хәзер зур кешеләр булдылар. Алар арасында дәрәҗәле җитәкчеләр, төрле белгечләр, танылган артистлар, бик яхшы укытучылар бар. Зур тормышка алар гимназия бусагасыннан ук әзер булып чыгалар.



Мин үзебезнең актлар залын тагын да зәвыклырак итеп күрергә телим. Анда яхшы аппаратура, профессиональ микрофоннар булса, оештырылган чаралар тагын да тәэсирлерәк булыр иде.

***Камилә Фәхретдинова***

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

***Гимназиябездә 16-23 нче гыйнвар көннәрендә Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең юбилеена багышланган атналык кысаларында төрле чаралар узды.***



“Өлге булырлык шәхес” темасына класс сәгатьләрендә укучылар Татарстанның беренче Президентының тормыш юлы, хезмәте белән таныштылар. Өлкән сыйныф укучылары өчен әтиләр советы тарафыннан оештырылган ча-рада Минтимер Шәрипович Шәймиев белән Мөслимдә бергә эшләгән хезмәттәшләре, аны күреп белгән шәхесләр катнашты.



Атна дәвамында фойеда урнаштырылган “Без Татарстанда яшибез!” күргәзмәсе белән танышырга мөмкинлек туды-рылды. “Лидерлык мәктәбе” исеме астында бәхәс-дәрестә 10 нчы а һәм б сыйныфы укучылары катнашты. Шулай ук гимназия укучылары командасы “Брейн-ринг” интеллектуаль уенының муниципаль турында уңышлы чыгыш ясадылар.



Гимназиянең “Әтиләр советы” тарафыннан 10 нчы а һәм б сыйныфы укучылары өчен Актаныш районы Әнәк авылында урнашкан Шәрип Шәймиевның Музей-йортына экскурсия оештырылды.



Музей-йорт йорты җитәкчесе Г.Ф.Гибадуллина Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең әти-әнисе, туган-нары турында бик мавыктыргыч итеп сөйләде. Шушы төбәктә 25 ел колхоз рәисе булып эшләгән Шәрип ага Шәймиев турында хатирәләр онытылмый, алар яңа буыннарга үрнәк итеп сөйләнелә. Дүрт бүлектән торган Музей-йортта Шәрип аганың үзе исән чакта кулланылган йорт җиһазлары: диван, телевизор, радиоалгыч, патефон, телефон аппараты, һ.б. бар, киеп йөргән күн тужуркасы, пыяла шкафта урын алган, шәхси истәлекләре саклана. Иң кыйммәтле экспонат – Шәймиевләрнең нәсел шәҗәрәседер, мөгаен.







Музей-йорттан халык өзелми. Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиевнең туган нигезе буларак, бу йорт безнең укучыларда зур кызыксыну уятты.

***Укучылар үзидарәсе***

## И Җ А Д И  С Ә Х И Ф Ә

### Татарстан – минем республикам

Минем илем, туган җирем,
Ул бит миңа бер генә.
Туган илем, туган җирем,
Бул син мәңге гөл генә!

Болыннарда йөрим җәен,
Саф һаваларын иснәп.
Кырда гөрләп үссә иген,
Пешәчәк күмәч, икмәк.

Туган җирем бик кадерле,
Бик матур һәм сөйкемле.
Якты йөзле, җылы нурлы
Таң кояшы шикелле.

Еракларга китсәм дә,
Сагынмыйча торалмам.
Татарстан – республикам!
Алсуланган багалмам!

****************

### Кайда?

Әни, кайда кояш бата?
Әни, кайда ай калка?
Кайдан кошлар куанышып,
Кайта безгә ерактан?

Кайда үсә кызыл алма?
Кайда үсә сарысы?
Ерак тауның битенә
Кайдан менеп карыйсы?

Кайда туган, кайда үскән,
Кеше – адәм баласы?
Сорауларым белән әле
Ерак-ерак барасы...

Сорау арты сорау туа,
Ничек белим барысын?
Килә минем бу дөньяның
Бөтен серен аңлыйсым.

****************

### *Бабаем*

Бабай озын гомер кичкән,
Карт ул үзе.
Ләкин һаман көлеп йөри,
Нурлы йөзле.

Бабаемны шатландырыйм –
Бер шигырь язам.
Ходай миңа әйтеп тора,
Барысын алдан.

Бәләкәй генә булсам да,
Гел үсеп барам.
Бабаемнан һәрвакыт
Мин үрнәк алам.

Сәламәт бул, озак яшә,
Минем бабаем.
Теләгемне кабул итсен
Берүк Ходаем.

****************

### *Татлы сүздән җан эри*

Йомшак телле, тәмле сүзле
Кыз булу җаен беләм.
Матур, ягымлы сүзләрнең
Тылсымлы көчен тоям.

Тәмле телем белән җайлап,
Сихерлим әбиемне.
Татлы сүземне кызганмыйм -
Сөендерәм әнине.

Әниемә – “әнкәем” дим,
Әтиемә – “әткәем”.
“Гөлкәем” дим гөлләргә,
“Пескәем” дим песигә.

Яхшы сүздән эрегәннәрен
Күргәнегез бармы соң?
Йомшак сүзне кызганмагыз,
Телегез арымасын.

***Лиана Хәбибуллина,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

### Әкиятләр тылсымы

Дәү әнием миңа сабый чакта
Сөйли иде әкият:
Гүзәл кызлар, Дию-пәри,
Су анасы утыра чәч тарап...

Кәҗә белән Сарык сәфәр чыккан,
Кемнәр белми Камырбатырны?
Бүгенгәчә озата бара
Әкиятләр шомы, тылсымы.

****************

### Туган телем

Чиста итеп саф татарча сөйлим,
“Кем өйрәтте сине?” – дип сора.
Йомшак сүзле газиз әнкәм:
“Бәбкәм,” - дип назлап тора.
Әтием дә, дусларым да
Саф татарча сөйләшә.
Туган телем - Тукай теле,
Гасырларда син яшә!

***Диләрә Нуриева,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

# И Җ А Д И  С Ә Х И Ф Ә

## Нәни булышчы

*Кичә мин бик тырыштым,*
*Әниемә булыштым.*
*Табак-савыт юыштым,*
*Келәмнәрне кагыштым.*

*Мин әтигә булыштым,*
*Аңа мунча ягыштым.*
*Магазинга барыштым –*
*Шуннан кайтып барышым.*

*Энем читтә калмады,*
*Аңа китап укыштым.*
*Полиция машинасын*
*Гаражына куештым.*

*Дәү әни күзлек югалткан,*
*Башта аны табыштым.*
*Бик яратам бабамны –*
*Аңа шахмат уйнаштым.*

*Тәмам арып беткәнмен,*
*Күпме эшләр эшләштем.*
*Дәресләрем искә төште -*
*Миңа кемнәр эшләшер?*

***Диләрә Нуриева,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

## Ятим Чыршы кызы турында әкият



Ерак түгел бер урман аланының нәкъ уртасында яшәгән, ди, булган, ди, бер Чыршы кызы. Чыршы кызы гомере буе япа-ялгыз икән. Иртән аны: “Тор, кызым,” – дип беркем иркәләп уятмый, усал җилләрдән ышыклап сакламый икән.

Шулай бик күп язлар, җәйләр, көзләр үткән. Бөтен җирне аклыкка күмеп, сафлыкка төреп, салкын кыш җиткән. Тирә-юньдәге агачлар бер-берсенә сыенып утыралар, үзара сөйләшеп алалар. Чыршы кызы һаман ялгыз. Аңа бик моңсу булып киткән, хәтта башы салынган, ботаклары асылынып төшкән, энәләре шиңгән кебек булган. Башка агачлар да Чыршы кызының хәлен сизеп алганнар, ләкин берничек ярдәм итә алмаганнар.

Ярый әле дуслар бар: куян малае Озынколак, тиен кызы Тиенкәй, чыпчыклар Чык белән Чырык көн саен аның янына киләләр. Чык белән Чырык ботакларга кунып качышлы уйныйлар, Озынколак белән Тиенкәй чыршы тирәли куышып йөрергә яраталар. Рәхәт була да соң ялгыз Чыршы кызына мондый вакытларда! Әниләре чакырып алгач, Чыршы кызы тагын моңаеп кала.

Көннәрдән беркөнне дуслар чыршыны Яңа елга бизәргә сүз куешканнар. Тиенкәй гөмбәләр, миләш тәлгәшләре алып килде, Озынколак матур уенчыклар, Чык белән Чырык төсле тасмалар элде.

Менә нинди матур Чыршы кызы! Алан уртасында балкып тора. Бу аның өчен иң бәхетле мизгелләр иде. Дуслары аңа ятимлек хисен онытып, үзен кирәкле итеп тоярга ярдәм иттеләр. Халыкта бик дөрес әйтем бар: “Иң ачы хис – ятимлек хисе”. Үзеңне кемгәдер кирәк икәнеңне белү яшәргә көч өсти.

***Диләрә Нуриева,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

## *Ятим чыршы кызы*

Борынгы заманнарда түгел, ә безнең гасырда яшәгән, ди, бик ишле гаилә - чыршылар гаиләсе. 100 еллык аксакал чыршы бабайлар, 70 яшьлек әби-бабайлар, 40-45 яшьлек урта буын абый-апалар, 10-15 еллык үсмер егет-кызлар, 1-5 яшьлек сабыйлар да булган араларында. Чыршылар искиткеч тату яшәгәннәр. Җәйге эсседә карт, чыдам бабалары яшь чыршыларны кызу кояш нурларыннан, кышкы чатнама салкыннарда, өшеткеч бураннардан саклаганнар.

Көннәрдән бер көнне. Чыршылар гаиләсенә авыр кайгы килә. Кешеләргә төзелеш өчен чиста, тигез урын кирәк була һәм алар, үз максатларына ирешер өчен, чыршы аланын бөтенләй юкка чыгаралар. Бик читтә үскән чыршы кызы гына исән кала. Чыршы кызы бик борчыла. Ятимлек ачысы аны тәмам кайгыга сала.

Байтак вакытлар уза. Чыршы кызы бик сылу, купшы агачка әверелә. Бу вакытка төзелеш эшләре дә тәмамлана. Ниһаять, зур йортларга кешеләр күченеп килә, ишек аллары җанлана. Чыршы тирәсендә балалар уйный, өлкәннәр ял итә торган урыннар булдырыла. Кыш җиткәч, өлкәннәр чыршы кызын гирлянда утлары белән бизиләр, балалар аның янында әйлән-бәйлән уйныйлар.

Быел яз көне тирә-якка шактый күп нарат үсентеләре алып килеп утырттылар. Аларга су сибеп йөргән балаларны күреп сөенә ул. Ятим чыршы кешеләргә баштарак рәнҗесә дә, бөтенләй кичерә алмас тоелса да, хәзер тынычланды. Күп тә үтмәс, аның янында нәни чыршылар үсеп китәр, элеккечә ишле гаиләсе булыр.

***Айзат Шәмсетдинов,***
***6 нчы б сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар-февраль, 2017 нче ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина
Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә
Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:**
Гилемов Азат
Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym